**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Төги авыл җирлегенең Олы Батрас торак пунктында 2025 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында гражданнар җыены**

**КАРАРЫ**

**12.11.2024** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Төги авыл җирлеге Олы Батрас торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Төги авыл җирлегенең Олы Батрас торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 600 (алты йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә, шул исәптән көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча һәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш.

2. Җыелган сумманы җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга:

- торак пункт территориясен төзекләндерү (балалар мәйданчыгына лементлар урнаштыру).

3. Карарны кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Төги авыл җирлеге мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

**Җыенда рәислек итүче,**
**җирлек башлыгы** **Т.В. Попова**